РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
Алькеевского
муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЬ
Әлки
муниципаль районы
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Базарлы Матак КАРАР

2023 елның 22 марты 75№

«2023 - 2025 елларга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасын раслау турында

Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 26 июлендәге «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте концепциясе турында» ПУ-695 номерлы Әмерен гамәлгә ашыру максатларында, гамәлдә булу срогы 2023 елга кадәр озайтылган «2014-2021 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программасын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты Карар бирә:

1. Яңа редакциядә «2023 - 2025 елларга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасын (алга таба - Программа) расларга.

2. Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 05 декабрендәге «2017 - 2020 елларга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасын раслау турында» 494 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУ ел саен чираттагы финанс елына район бюджетын формалаштырганда, Әлки муниципаль районы бюджетыннан әлеге максатларга җибәрелә торган акчалар чикләрендә, мөмкинлекләрне исәпкә алып, Программа чараларын тормышка ашыру өчен күрсәтелгән максатларга җибәрелә торган финанс чараларын күздә тотарга.

4. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының җирле үзидарә органнарына, иҗтимагый оешмаларга һәм берләшмәләргә Программа чараларын гамәлгә ашыруда катнашырга тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарны alkeevskiy.tatarstan.ru адресы буенча Әлки муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Әлки муниципаль районы Башкарма
комитет җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы С.Н.Балакирев

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитетының 2023
елның 22 мартындагы 75№
карарына кушымта

**«2023 - 2025 ЕЛЛАРГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА ДӘҮЛӘТ МИЛЛИ СӘЯСӘТЕН ГАМӘЛГӘ АШЫРУ» МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ**

**ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ**

| | |
|---|---|
| Программа исеме | "2023-2025 елларга Әлки муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру" муниципаль программасы |
| Программаны эшләү өчен нигезләр | Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 19 декабрендәге 1666 номерлы Әмере белән расланган 2025 елга кадәр чорга Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәте стратегиясе<br>Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 26 июлендәге "Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте концепциясе турында" УП-695 номерлы Әмере<br>"2014-2020 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру" дәүләт программасы<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 18 декабрендәге «2014 - 2020 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 1006 номерлы карары |
| Программаны төп эшләүче | Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программа максатлары | Әлки муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру, Әлки муниципаль районы территориясендә яшәүче халык вәкилләренең цивилизацияле үсеше, милләтара һәм конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны саклау, гомумроссия граждан тәңгәллеген (Россия милләтен) ныгыту, мигрантларның уңышлы социаль һәм мәдәни адаптациясе һәм интеграциясе |
| Программа бурычлары | 1. Әлки муниципаль районы территориясендә яшәүче халык вәкилләренең милли-мәдәни үсешенә ярдәм итү һәм гомумроссия граждан тәңгәллеген ныгыту;<br>2. Әлки муниципаль районы территориясендә дәүләт милли сәясәте өлкәсендә дәүләт һәм муниципаль органнарның гражданлык җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлеген камилләштерү;<br>3. Мигрантларның этникара һәм конфессияара татулыгына һәм дуслыгына, социомәдәни җайлашуына һәм интеграциясенә шартлар тудыру һәм ярдәм итү;<br>4. Республика һәм районнан читтә татар халкының милли тиңдәшлеген саклап калу һәм үстерү өчен шартлар тудыруда ярдәм күрсәтү;<br>5. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль |

| | |
|---|---|
| | районында татар, рус һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү өчен шартлар тудыру;<br>6. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруны фәнни-мәгариф һәм мәгълүмати тәэмин итү;<br>7. Программа куйган бурычларны үтәү кысаларында республика, бөтенроссия, халыкара бәйге һәм фестивальләрдә катнашу |
| Ярдәмче программалар исемлеге | «Әлки муниципаль районында террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау» |
| Программаны тормышка ашыру срогы | 2023 - 2025 еллар |
| Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Программаны финанслау күләме район бюджеты акчалары исәбеннән хисабына 3 303 700 сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2023 елда -981 000 сум;<br>2024 елда - 1 099 700 сум;<br>2025 елда - 1 223 000сум.<br>Искәрмә: финанслау күләме фаразланган характерда һәм район бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш. |
| Программаны гамәлгә ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре (программа нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Программа индикаторлары<br>1.Әлки муниципаль районында яшәүчеләрнең райондагы этник мөнәсәбәтләрнең торышын уңай бәяләүче өлеше арту (репрезентатив сораштыру нәтиҗәләре буенча билгеләнә):<br>2023 елда - 72,5 %;<br>2024 елда - 72,8 %;<br>2025 елда - 73 %;<br>2. Әлки муниципаль районында яшәүчеләрнең райондагы конфессияара мөнәсәбәтләрнең торышын уңай бәяләүче өлеше арту (репрезентатив сораштыру нәтиҗәләре буенча билгеләнә):<br>2023 елда - 70 %;<br>2024 елда - 72 %;<br>2025 елда - 74 %;<br>3. Әлки муниципаль районында яшәүчеләрнең этномәдәни ихтыяҗларын гамәлгә ашыру белән канәгать булган өлеше арту (репрезентатив сораштыру нәтиҗәләре буенча билгеләнә):<br>2023 елда - 68%;<br>2024 елда - 69 %;<br>2025 елда - 70 %; |

## I. Программаны гамәлгә ашыру өлкәсенә гомуми характеристика, шул исәптән ул хәл итүгә юнәлдерелгән проблемалар

"2023-2025 елларга Әлки муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру" муниципаль программасы Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 26 июлендәге "Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте концепциясе турында" УП-695 номерлы Әмере һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 18 декабрендәге «2014 - 2020 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 1006 номерлы карары нигезендә эшләнгән. Программа дәүләт хакимиятенең территориаль органнары, Әлки муниципаль районының җирле үзидарә органнары, Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты, музейлар, мәгариф учреждениеләре һәм иҗтимагый оешмалар тәкъдимнәрен исәпкә алып эшләнде.

Татарстан Республикасы дәүләт милли сәясәте концепциясе нигезендә, дәүләт милли сәясәте объекты булып Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең милләтара мөнәсәбәтләр һәм этномәдәни үсеш өлкәсе тора.

Татарстан Республикасы Дәүләт милли сәясәте концепциясе принципларына таянып, Программа Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыруның максатларын, принципларын, төп юнәлешләрен, бурычларын һәм механизмнарын, районда яшәүче халыкларның этномәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен оптималь шартлар булдыруны билгели. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында яшәүче халык вәкилләренең тарихи традицияләрен, табигый-климатик һәм табигый-икътисадый шартларны, аларның тормыш-көнкүрешенең социаль-мәдәни үзенчәлекләрен, геосәяси һәм милли чолганышны, күршеләр белән үзара мөнәсәбәтләр тәҗрибәсен аңлауга таяна.

Тарихи яктан, уңай милләтара (этникара) һәм конфессияара хезмәттәшлекне тәэмин итүдә традицион рәвештә Татарстан Республикасының Әлки муниципаль районында яшәүче башка халыклар вәкилләренә карата күпчелекне тәшкил итүче татар һәм рус халыклары вәкилләре төп роль уйный.

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында 18481 кеше яши:

татарлар - 11589 кеше (62, 9%)
чувашлар - 3277 кеше (17,8%)
руслар - 3285 кеше (17,8%)
башкалар - 250 кеше (1,5%).

Татарстанда төрле мәдәният һәм дин вәкилләренең озак еллар бергә яшәүләре дәвамында урнашкан дус-тату яшәү традицияләре хәзерге вакытта да саклана.

Әлки муниципаль районында, бөтен республикадагы кебек үк, халыкның милли составы динамик рәвештә үзгәрә - авыл җирлекләрендә

элеккеге союздаш республикалардан килгән яңа этник төркемнәр барлыкка килә (азәрбайҗан, әрмән, үзбәк, таҗик).

Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 26 июлендәге "Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте концепциясе турында" УП-695 номерлы Әмере белән әлеге өлкәдә хәзерге этапта өстенлекле мәсьәләләр билгеләнде.

Әлеге Программа Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрнең уңай характерын саклауга юнәлдерелгән.

Программа планына үзара ихтирам һәм игелеклелекнең күпгасырлык традицияләре нигезендә гражданнарның этномәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә ярдәм итүче оештыру, мәдәни-массакүләм һәм мәгариф чаралары кертелгән.

## II. Төп максатлар, бурычлар, сроклар һәм гамәлгә ашыру этаплары

Программаның максаты һәм бурычлары Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 19 декабрендәге 1666 номерлы Әмере белән расланган 2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәте стратегиясе һәм Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте концепциясе (2013 елның 26 июлендәге редакциядә), федераль һәм региональ законнар һәм Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте өлкәсенә кагылышлы норматив хокукый актлар белән билгеләнгән өстенлекле юнәлешләргә бәйле. Программа максаты:

Әлки муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру, Әлки муниципаль районы территориясендә яшәүче халык вәкилләренең цивилизацияле үсеше, милләтара һәм конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны саклау, гомумроссия граждан тәңгәллеген (Россия милләтен) ныгыту, мигрантларның уңышлы социаль һәм мәдәни адаптациясе һәм интеграциясе

Программа бурычлары:

1. Әлки муниципаль районы территориясендә яшәүче халыкларның милли-мәдәни үсешенә ярдәм итү һәм гомумроссия гражданлык тәңгәллеген ныгыту;

2. Дәүләт һәм муниципаль органнарның Татарстан Республикасында һәм турыдан туры Әлки муниципаль районы территориясендә дәүләт милли сәясәте өлкәсендә гражданлык җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлеген камилләштерү;

3. Мигрантларның этникара һәм конфессияара татулыгына һәм дуслыгына, социомәдәни җайлашуына һәм интеграциясенә шартлар тудыру һәм ярдәм итү;

4. Республика һәм районнан читтә татар халкының милли тиңдәшлеген саклап калу һәм үстерү өчен шартлар тудыруда ярдәм күрсәтү;

5. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында татар, рус һәм башка телләрне саклап калу, өйрәнү һәм үстерү өчен шартлар тудыру

6. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруны фәнни-мәгариф һәм мәгълүмати тәэмин итү.

Программаны гамәлгә ашыру срогы: 2023-2025 еллар. Тормышка ашыру этаплары билгеләнми. Программаның максатлары, бурычлары, чаралары киселешендәге нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары турында мәгълүматлар аңа кушымтада китерелә.

## III. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Программаны финанслау күләме район бюджеты акчалары исәбеннән 3 303 700 сум тәшкил итә, шул исәптән: 2023 елда - 981 000сум; 2024 елда - 1 099 700 сум, 2025 елда - 1 223 000 сум.

Искәрмә: финанслау күләме фаразланган характерда һәм район бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

Программада бюджеттан тыш акчаларны (эшмәкәрләр, иганәчеләр акчасы) җәлеп итү мөмкинлеге каралган.

## IV. Программаны гамәлгә ашыру механизмы

Программа чараларын гамәлгә ашыру барышында Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты йөзендә заказчы-координатор төп башкаручыларның үзара хезмәттәшлеген, чараларны гамәлгә ашыру барышын һәм башкаручылар тарафыннан акчаларны нәтиҗәле файдаланылуын тикшереп торуны тәэмин итә. Программа чаралары муниципаль заказчы тарафыннан Программа чараларын башкаручылар белән гамәлгә ашырыла торган муниципаль контрактлар нигезендә гамәлгә ашырыла

Программаны гамәлгә ашыруда катнашучы муниципаль учреждениеләр һәм оешмалар Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетына квартал саен аның үтәлеше турында мәгълүматны хисап кварталыннан соң килүче айның 15 числосына кадәр тапшыралар.

## V. Программаның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеген тасвирлау

Этномәдәни өлкәдәге төп нәтиҗәләр, кагыйдә буларак, вакыт буенча кичектерелгән социаль эффектта, аерым алганда, төрле халыклар вәкилләренең мәдәниятенә, теленә һәм традицияләренә карата толерантлык һәм хөрмәт үсүендә, кешеләрнең үз-үзләрен тотышының кыйммәт ориентацияләрен һәм нормаларын уңай үзгәртүдә, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының тотрыклы үсешенең мөһим факторы буларак Бердәм этномәдәни киңлекне үстерүдә чагыла.

Программаны тормышка ашыруның социаль-икътисади эффекты социаль тотрыклылыкны, этник һәм конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны, этномәдәни үзенчәлекне саклау һәм Әлки муниципаль районында яшәүче халыкларның социаль-мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерүдән гыйбарәт һәм чагыла:

этномәдәни һәм социаль халәтне яхшыртуда;

региональ һәм гомумроссия граждан тәңгәллеген ныгытуда;

этномәдәни потенциалны файдалануның нәтиҗәлелеге артуда;

милләтара конфликтларны булдырмый калуда;

Программаны гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында яшәүче халык вәкилләренең милләтара (этникара) һәм конфессияара уңай хезмәттәшлеген, этник һәм конфессия нигезендә конфликтларны профилактикалауны һәм кисәтүне, мигрантларны адаптацияләү өчен шартлар тудыруны тәэмин итәчәк.

| Чаралар атамасы | Башкаручылар | Гамәлгә ашыру сроклары | Чыганагы күрсәтелгән финанслау күләме, сум | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| **1. Бурычы: Әлки муниципаль районы территориясендә яшәүче халык вәкилләренең милли-мәдәни үсешенә ярдәм итү һәм гомумроссия граждан тәңгәллеген ныгыту** | | | | | |
| 1.1 Традицион халык бәйрәмнәре һәм йолалары (Сабантуй, Уяв, Масленица, Нәүрүз, Яңа ел тамашалары һ.б.) | ҖҮО<br><br>«Мәгариф идарәсе» МКУ<br><br>«ӘМР Әлки район мәдәният бүлеге» МКУ<br><br>ТР ӘМР БК ЯСhСБ<br><br>«Алькеевские вести» - «Әлки хәбәрләре» район газетасы редакциясе | 2023-2025 еллар | 170 000<br><br>200 000 | 175 000<br><br>210 000 | 180 000<br><br>220 000 |
| 1.2. Календар бәйрәмнәр (Ватанны саклаучылар көне, Халыкара хатын-кызлар көне, Җиңү көне, Балаларны яклау көне, Өлкәннәр көне, инвалидлар көне, Ватан Геройлары көне, Халыклар бердәмлеге көне һ.б.) | ҖҮО<br><br>«Мәгариф идарәсе» МКУ<br><br>«Әлки район мәдәният бүлеге» МКУ<br><br>ТР ӘМР БК ЯСhСБ<br><br>«Алькеевские вести» - «Әлки хәбәрләре» район газетасы редакциясе | 2023-2025 еллар | 35 000<br><br>100 000 | 40 000<br><br>110 000 | 45 000<br><br>120 000 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | ТР ӘМР “ҮК” МБМУ | | | | |
| 1.3. Агитбригадалар, театральләштерелгән тамашалар, рус һәм татар телләрендә тематик программалар һәм күңел ачу программалары, Әлки муниципаль районы территориясендә гражданлык бердәмлеген нығыту темаларын чагылдыра торган милли көрәш турнирлары. | ҖҮО<br><br>«Мәгариф идарәсе» МКУ<br><br>«Әлки район мәдәният бүлеге» МКУ<br><br>ТР ӘМР БК ЯСhСБ<br><br>«Алькеевские вести» - «Әлки хәбәрләре» район газетасы редакциясе | 2023-2025 еллар | 25 000 | 30 000 | 35 000 |
| 1.4. Смотрлар, бәйгеләр, халык иҗаты фестивальләре.<br>- Балалар өчен "Йолдызлык" смотр-бәйгесе<br>- фольклор коллективларның смотр-бәйгесе<br>- "Рус җыры" смотр-бәйгесе. «Татар җыры»<br>- Өлкәннәр иҗат фестивале.<br>- Инвалидлар иҗат фестивале<br>- Татар җырын башкаручы яшь башкаручыларның смотр-бәйгесе | ҖҮО<br><br>«Мәгариф идарәсе» МКУ<br><br>«Әлки район мәдәният бүлеге» МКУ<br><br>«Алькеевские вести» - «Әлки хәбәрләре» район газетасы редакциясе | 2023-2025 еллар | 30 000<br><br><br><br><br>40 000 | 30 000<br><br><br><br><br>45 000 | 30 000<br><br><br><br><br>50 000 |
| 1.5. "Безнең уртак йортыбыз-Татарстан" яшүсмерләр хокукый мәктәп эше.<br>Чаралар циклы.<br>- Милләтара мөнәсәбәтләр | «Мәгариф идарәсе» МКУ | 2023-2025 еллар | 10 000 | 11 000 | 12 000 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| өлкәсендә экстремизмны һәм хокук бозуларны профилактикалау буенча лекция.<br>- Тематик программа<br>- "Россия күпмилләтле дәүләт" телдән журнал.<br>- "Иң яхшы толерант тәртип белгече" ИКТ кулланып уеннар.<br>“Мин - Россия гражданины” акциясе кысаларында паспортлар тапшыру буенча тантаналы чара | | | | | |
| 1.6. Халыкара толерантлык көненә багышланган чаралар циклы:<br>- "Яхшылык дөньяны коткарыр" фотоэшләр бәйгесе.<br>"Без, төрле халык балалары, дуслык турында хыял белән яшибез" дигән балалар рәсеме бәйгесе.<br>- Хокук саклау органнары катнашында түгәрәк өстәл артында әңгәмә | «Мәгариф идарәсе» МКУ<br><br>«Әлки район мәдәният бүлеге» МКУ,<br><br>«Алькеевские вести» - «Әлки хәбәрләре» район газетасы редакциясе | 2023-2025 еллар | 10 000 | 11 000 | 12 000 |
| 1.7. Хокук саклау органнары белгечләрен һәм хезмәткәрләрен җәлеп итеп, "Экстремизмга - юк!" тематик дискотекалар | «Әлки район мәдәният бүлеге» МКУ<br><br>ТР ӘМР БК ЯСhСБ<br><br>«Алькеевские вести» - «Әлки хәбәрләре» район газетасы редакциясе | 2023-2025 еллар | 10 000 | 12 000 | 14 000 |
| 1.8. Республика бәйгеләрендә һәм фестивальләрендә катнашу: | «Әлки район мәдәният бүлеге» | 2023-2025 еллар | 20 000 | 25 000 | 30 000 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| - «Татарстан - йортыбыз» этномәдәни фестивале<br>- «Радуга - Салават күпере» милли мәдәниятләр балалар-яшүсмерләр фестивале<br>- иҗади балалар һәм яшьләр өчен "Дулкыннар" ( "Волны") бәйгесе .<br>- "Ватан" халык иҗаты һәм декоратив-гамәли сәнгать фестиваль-бәйгесе<br>- «Каравон» фестивале, «УЕН ФЕСТ» республика уеннары фестивале һәм башкалар. | МКУ<br><br>«Алькеевские вести» - «Әлки хәбәрләре» район газетасы редакциясе | | | | |
| 1.9. Татарстан Республикасы көненә багышланган чаралар үткәрү | ҖҮО<br><br>«Мәгариф идарәсе» МКУ<br><br>«Әлки район мәдәният бүлеге» МКУ<br><br>ТР ӘМР БК ЯСhСБ<br><br>«Алькеевские вести» - «Әлки хәбәрләре» район газетасы редакциясе<br><br>ТР ӘМР “ҮК” МБМУ җирлекләр | 2023-2025 еллар | 12 000<br><br>20 000 | 15 000<br><br>25 000 | 17 000<br><br>30 000 |
| 1.10. Халыкара туган телләр көнен, Туган тел көнен һәм Рус теле көнен бәйрәм итүгә багышланган еллык чаралар комплексын оештыру һәм үткәрү | «Мәгариф идарәсе» МКУ<br><br>«Әлки район мәдәният бүлеге» | 2023-2025 еллар | 15 000 | 17 000 | 20 000 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | МКУ<br><br>«Алькеевские вести» - «Әлки хәбәрләре» район газетасы редакциясе<br><br>ТР ӘМР “ҮК” МБМУ | | | | |
| 1.11. "Милли кухня көне" муниципаль бәйге-фестивале | ҖҮО<br><br>«Алькеевские вести» - «Әлки хәбәрләре» район газетасы редакциясе | 2023-2025 еллар | 5 000 | 6 000 | 8 000 |
| 1.12. Дини бәйрәмнәргә багышланган чаралар комплексын эшләү һәм уздыру | ҖҮО<br><br>«Әлки район мәдәният бүлеге» МКУ<br><br>«Алькеевские вести» - «Әлки хәбәрләре» район газетасы редакциясе | 2023-2025 еллар | 15 000 | 17 000 | 20 000 |
| 1.13. Татарстан халыклары телләренә багышланган чаралар комплексын эшләү һәм уздыру | «Мәгариф идарәсе» МКУ<br><br>«Әлки район мәдәният бүлеге» МКУ<br><br>«Алькеевские вести» - «Әлки хәбәрләре» район газетасы редакциясе | 2023-2025 еллар | 10 000 | 12 000 | 15 000 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | ТР ӘМР “ҮК” МБМУ | | | | |
| 1.14. ТР территориясендә яшәүче халыкларның халык фольклоры үзенчәлекләре турында сөйләүче чаралар циклы | «Мәгариф идарәсе» МКУ<br><br>«Әлки район мәдәният бүлеге» МКУ<br><br>ТР ӘМР “ҮК” МБМУ<br><br>«Алькеевские вести» - «Әлки хәбәрләре» район газетасы редакциясе | 2023-2025 еллар | 8 000 | 10 000 | 13 000 |
| **2. Бурычы: Дәүләт һәм муниципаль органнарның Татарстан Республикасында һәм турыдан туры Әлки муниципаль районы территориясендә дәүләт милли сәясәте өлкәсендә гражданлык җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлеген камилләштерү** | | | | | |
| 2.1. Әлки муниципаль районында Дәүләт милли сәясәте концепциясен гамәлгә ашыру буенча программалар эшләү һәм кабул итү | ҖҮО | 2023-2025 еллар | _____ | _____ | _____ |
| 2.2. Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең милли-мәдәни автономияләр җитәкчеләренең Татарстан Республикасы дәүләт милли сәясәте Концепциясен гамәлгә ашыруда катнашу мәсьәләсе буенча республика киңәшмәләрендә катнашу | ҖҮО | 2023-2025 еллар | _____ | _____ | _____ |
| 2.3. Татарстан Республикасы | ҖҮО | 2023-2025 | _____ | _____ | _____ |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| дәүләт милли сәясәте концепциясен гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча авыл җирлекләре башлыклары, Башкарма комитет, социаль яклау, хокук саклау органнары, культ учреждениеләре җитәкчеләре белән район семинар-киңәшмәләрен үткәрү | «Алькеевские вести» - «Әлки хәбәрләре» район газетасы редакциясе | еллар | | | |
| 2.4. Дини оешмалар, иҗтимагый һәм милли берләшмәләр эшчәнлеген гамәлгә ашыручы муниципаль хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү | ҖУО | 2023-2025 еллар | 10 000 | 10 000 | 10 000 |
| 2.5. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр өлкәсендә эшчәнлек алып баручы социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм оештыру | ҖУО | 2023-2025 еллар | 8 000 | 9 000 | 10 000 |
| 2.6. Гражданнарның милләтенә, теленә, дини ышануларына, шулай ук эшкә кабул иткәндә, кадрлар резервын рәсмиләштергәндә гражданнарның тигез хокуклылыгын бозу фактлары турындагы мөрәҗәгатен мониторинглау. | ҖУО<br><br>Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Әлки муниципаль районы буенча җәмәгать ярдәмчесе | 2023-2025 еллар | _____ | _____ | _____ |
| 2.7. Милләтара, конфессиональ мөнәсәбәтләр буенча ведомствоара эш төркеме эшчәнлеген оештыру | ҖУО<br><br>«Алькеевские вести» - «Әлки хәбәрләре» район газетасы | 2023-2025 еллар | _____ | _____ | _____ |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | редакциясе | | | | |
| 2.8. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында дини, этник, гастрономик һәм экологик туризмны үстерү | ЖҮО | 2023-2025 еллар | 6 000 | 6 500 | 7 000 |
| 2.9. Милләтара, динара мөнәсәбәтләргә багышланган чаралар | ЖҮО<br><br>«Мәгариф идарәсе» МКУ<br><br>«Әлки район мәдәният бүлеге» МКУ<br><br>ТР ӘМР БК ЯСhСБ<br><br>«Алькеевские вести» - «Әлки хәбәрләре» район газетасы редакциясе | 2023-2025 еллар | 15 000<br><br>20 000 | 17 000<br><br>22 000 | 20 000<br><br>24 000 |
| 2.10. эш мигрантлары өчен Россия, Татарстан тарихын һәм РФ, ТР законнарының нигезләрен ача торган китап күргәзмәләрен оештыру | ТР ӘМР “ҮК” МБМУ | 2023-2025 еллар | 1000 | 1500 | 2000 |
| 2.11. "Киләчәккә ераграк караган саен, үткәннәр кыйммәтләнә": Татарстан халыклары чыганаклары. Чаралар циклы | ТР ӘМР “ҮК” МБМУ | 2023-2025 еллар | 1000 | 1500 | 2000 |
| **3. Бурычы: Милләтара һәм конфессияара тынычлык һәм татулыкка, мигрантларның социаль мәдәни адаптациясенә һәм интеграциясенә шартлар тудыру һәм ярдәм итү** | | | | | |
| 3.1. Әлки муниципаль районында чит ил эшче көчләрен җәлеп итү, сайлап алу һәм алардан файдалану механизмнарын камилләштерү | ЖҮО | 2023-2025 еллар | ——— | ——— | ——— |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 3.2. Әлки муниципаль районында мигрантларны хокукый агарту, социаль-мәдәни адаптацияләүдә һәм интеграциядә ярдәм күрсәтү буенча чаралар курсы | ЖҮО<br><br>«Алькеевские вести» - «Әлки хәбәрләре» район газетасы редакциясе | 2023-2025 еллар | _____ | _____ | _____ |
| 3.3. "Тигез хокуклар гарантиясе": Конституция көненә чаралар циклы<br>"Мин, син, ул - бергә тату гаилә!" Музей-педагогик чарасы<br>Халыкара тынычлык көненә "Ислам мәдәнияте чыганаклары"<br>"Ерак үткәннәрдә туган ягым" танып белү сәгате | ЖҮО<br><br>«Мәгариф идарәсе» МКУ<br><br>«Әлки район мәдәният бүлеге» МКУ<br><br>ТР ӘМР БК ЯСhСБ<br><br>«Алькеевские вести» - «Әлки хәбәрләре» район газетасы редакциясе | 2023-2025 еллар | 3000 | 3 500 | 4 000 |
| **4. Бурычы: республикадан һәм районнан читтә татар халкының милли тиңдәшлеген саклап калу һәм үстерү өчен шартлар тудыруда ярдәм күрсәтү** | | | | | |
| 4.1. ТР МК графигы буенча төбәк татар милли-мәдәни автономияләренә "Сабантуй" бәйрәмен үткәрүдә ярдәм күрсәтү | ЖҮО<br><br>«Мәгариф идарәсе» МКУ<br><br>«Әлки район мәдәният бүлеге» МКУ<br><br>ТР ӘМР БК ЯСhСБ | 2023-2025 еллар | 60 000 | 65 000 | 70 000 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | «Алькеевские вести» - «Әлки хәбәрләре» район газетасы редакциясе | | | | |
| **5. Бурычы: Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында татар, рус һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү өчен шартлар тудыру** | | | | | |
| 5.1. "Сүз - беренче": Славян язуы һәм мәдәнияте көненә чаралар циклы<br>- Татар теле көненә багышланган тематик программалар.<br>- Рус теле көненә багышланган шигъри кичәләр | ҖУО<br><br>«Әлки район мәдәният бүлеге» МКУ<br><br>«Алькеевские вести» - «Әлки хәбәрләре» район газетасы редакциясе | 2023-2025 еллар | _____ | _____ | _____ |
| 5.2. Әлки муниципаль районы гомуми белем бирү мәктәпләре укучылары өчен ел саен үткәрелә торган шигърият бәйрәмен, А.С. Пушкин туган көнгә рус теле фестивален үткәрү | «Мәгариф идарәсе» МКУ<br><br>«Әлки район мәдәният бүлеге» МКУ<br><br>«Алькеевские вести» - «Әлки хәбәрләре» район газетасы редакциясе | 2023-2025 еллар | 10 000 | 15000 | 20 000 |
| 5.3. Татар һәм рус телләрендә яшь әдәбиятчыларның еллык бәйгеләрен үткәрү ("Иделем акчарлагы", "Яңа татар пьесасы") | «Мәгариф идарәсе» МКУ<br><br>«Әлки район мәдәният бүлеге» МКУ<br><br>«Алькеевские вести» - «Әлки хәбәрләре» | 2023-2025 еллар | 10 000 | 15000 | 20 000 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | район газетасы редакциясе | | | | |
| **6. Бурычы: Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруны фәнни-мәгариф һәм мәгълүмати тәэмин итү** | | | | | |
| 6.1. Китапханә фондларын Россия халыклары әсәрләренең татар һәм рус телләрендәге тәрҗемәләре белән тулыландыру | ТР ӘМР “ҮК” МБМУ | 2023-2025 еллар | 30 000 | 35 000 | 40 000 |
| 6.2. Без тигез хокуклы халык: Милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне гармонизацияләүгә төрле халыкларның мәдәнияте, гореф-гадәтләре һәм юнәлешләре белән таныштыручы әдәби чаралар | ТР ӘМР “ҮК” МБМУ<br><br>«Алькеевские вести» - «Әлки хәбәрләре» район газетасы редакциясе | 2023-2025 еллар | 5000 | 5500 | 6000 |
| 6.3. Китапханәләр фондын Татарстан халыклары турында җыентыклар белән тулыландыру | ТР ӘМР “ҮК” МБМУ | 2023-2025 еллар | 15 000 | 17 000 | 18 000 |
| 6.4. "Йортыбыз - Татарстан" республика этномәдәни фестивалендә катнашу | ҖҮО<br><br>«Мәгариф идарәсе» МКУ<br><br>«Әлки район мәдәният бүлеге» МКУ | 2023-2025 еллар | 8 000 | 9 000 | 10 000 |
| 6.5. "Радуга - Салават күпере" милли мәдәниятләр республика балалар-яшүсмерләр фестивалендә катнашу | «Мәгариф идарәсе» МКУ<br><br>«Әлки район мәдәният бүлеге» МКУ<br><br>«Алькеевские вести» - «Әлки хәбәрләре» | 2023-2025 еллар. | 20 000 | 25 000 | 30 000 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | район газетасы редакциясе | | | | |
| 6.6. «Ватан» халык иҗаты һәм декоратив-гамәли сәнгать республика фестиваль-бәйгесендә катнашу | «Мәгариф идарәсе» МКУ<br><br>«Әлки район мәдәният бүлеге» МКУ<br><br>ТР ӘМР БК ЯСhСБ<br><br>«Алькеевские вести» - «Әлки хәбәрләре» район газетасы редакциясе | 2023-2025 еллар | 20 000 | 25 000 | 30 000 |
| 6.7 «УЕН ФЕСТ» традицион уеннарның республика фестивалендә катнашу | «Әлки район мәдәният бүлеге» МКУ | 2023-2025 еллар | 10 000 | 12 000 | 14 000 |
| 6.7. Белгечләр җәлеп итеп, Әлки муниципаль районында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр торышына мониторинг үткәрү | ҖҮО<br><br>«Мәгариф идарәсе» МКУ<br><br>«Әлки район мәдәният бүлеге» МКУ<br><br>ТР ӘМР БК ЯСhСБ<br><br>«Алькеевские вести» - «Әлки хәбәрләре» район газетасы редакциясе | 2023-2025 еллар | 2 000 | 2 100 | 2 500 |
| 6.8. Әлки муниципаль районында Дәүләт милли сәясәте | Әлки муниципаль районы Башлыгы | 2023-2025 еллар | 2 000 | 2 100 | 2 500 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| концепциясен гамәлгә ашыру турында еллык докладны әзерләү | каршындагы милләтара мөнәсәбәтләр советы | | | | |

**Файдаланылган кыскартулар исемлеге:**

- ӘМР ҖҮО- Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының җирле үзидарә органнары
- «Әлки районы мәдәният бүлеге» МКУ - «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы мәдәният бүлеге» муниципаль казна учреждениесе
- «Мәгариф идарәсе» МКУ - «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе
- ТР ӘМР БК ЯСhСБ - Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте һәм спорт бүлеге

ТР ӘМР "ҮК" МБМУ - «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Әлки Поселокара үзәк китапханәсе» Муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе